| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.10.2023 Ульянково ав. №60

Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге территориясендә урнашкан каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларының реестрын һәм урнаштыру схемасын раслау турында

"Рәссия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Җитештерү һәм куллану калдыклары турында" 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясындагы 4 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 августындагы 1039 номерлы карары белән расланган каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарын (мәйданчыкларын) һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре нигезендә, Кайбыч муниципаль районының Ульянковоавыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районының Ульянковоавыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау урыннары реестрын расларга (1 нче кушымта).

2. Кайбыч муниципаль районының Ульянковоавыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын урнаштыру схемасын расларга (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянковоавыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Ульянково авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Ф.А.Сундурова

Кайбыч муниципаль районы
Ульянковоавыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023е. октябрендеге 60
номерлы карарына
1 нче кушымта

## Кайбыч муниципаль районының Ульянковоавыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау урыннары реестры

| N | Контейнер мәйданчыгының милекчесе (хуҗасы) | Контейнер мәйданчыгының урнашу урыны | Контейнерлар саны (данә) | Контейнерларның күләме (м3) | мәйданчыкка җыела торган каты көнкүреш калдыклары барлыкка килү чыганаклары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Башкарма комитеты | ТР, Кайбыч районы, Ульянково ав., Мәктәп ур. | 2 | 2 | Ульянково ав., Мәктәп ур. |
| 2 | Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Башкарма комитеты | ТР, Кайбыч районы, Ульянково ав., Зур ур. | 2 | 2 | Ульянково ав., Зур ур. |
| 3 | Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Башкарма комитеты | ТР, Кайбыч районы, Корноухово ав., Бутанина ур. | 2 | 2 | Корноухово ав., Бутанина ур. |
| 4 | Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Башкарма комитеты | ТР, Кайбыч районы, Корноухово ав., Бутанина ур. | 2 | 2 | Корноухово ав., Бутанина ур. |
| 5 | Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Башкарма комитеты | ТР, Кайбыч районы, Победа ав., Залесная ур. | 2 | 2 | Победа ав., Заречная ур. |
| 6 | Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Башкарма комитеты | ТР, Кайбыч районы, Воскресенский ав., Леваневского ур. | 2 | 2 | Воскресенский ав., Леваневского ур. |

каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарының (мәйданчыкларының) урнашу урыны турында мәгълүматлар;


каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарының (мәйданчыкларының) техник характеристикалары турында мәгълүматлар;

каты коммуналь калдыкларны туплау урыннары (мәйданчыклары) милекчеләре турында мәгълүматлар;

каты коммуналь калдыкларны туплау урынында (мәйданчыгында) туплана торган каты коммуналь калдыклар барлыкка килү чыганаклары турында мәгълүматлар.

Кайбыч муниципаль районы
Ульянковоавыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023е. октябрендеге 60
номерлы карарына
2 нче кушымта

Ульянково авылы янында каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру схемасы



Корноухово ав. каты коммуналь калдыклар жыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру схемасы



Победа ав. каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру схемасы



Воскресенский авылындагы каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру схемасы

